**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село
Черемшан,
423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 32 ейорт,
Чирмешәнавылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42,

email:Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

# КАРАР

«13» июнь 2019 ел **Чирмешән авылы** **№247**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» гы 2018 елның 16 ноябрендәге 531 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 16 ноябрендәге 531 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» нигезләмәсенә (2019 елның 21 мартындагы 106 номерлы үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләр кертергә.

1.1. 1 бүлегендәге 2 пунктның 4 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Оклад (вазыйфаи оклад) - календарь ае өчен компенсация, стимуллаштыра торган һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәр хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме».

1.2. 1 бүлегендәге 2 пунктның 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «база оклады (база вазыйфаи оклад), хезмәт хакының база ставкасы - минималь хезмәт хакы (вазыйфаи оклад), тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәр

һөнәре буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы дәүләт яисә муниципаль учреждение хезмәткәренең эш хакы ставкасы, компенсация, стимуллаштыра торган һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин